**УКАЗ**
ПРЕЗИДЕНТА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ПРЕЗИДЕНТЫ
**УКАЗЫ**

**Татарстан Республикасы Азнакай районының Мәнәвез авылы территориясендә терлекләр котыру авырулы булганга, аның иминлексезлеге сәбәпле карантин кертү турында**

Терлекләрнең котыру авырулы булуы ачыклану һәм аның Татарстан Республикасы торак пунктларында таралу куркынычы белән бәйле рәвештә, «Ветеринария турында» 1993 елның 14 маендагы 4979-I номерлы Россия Федерациясе Законының $3^1$, 17 статьялары нигезендә **карар бирәм:**

1. Татарстан Республикасы Азнакай районының Мәнәвез авылы территориясендә терлекләр котыру авырулы булганга, аның иминлексезлеге сәбәпле карантин кертергә.

2. Әлеге Указның 1 пунктында күрсәтелгән территориядә карантин гамәле дәвам иткән вакытта түбәндәгеләр тыела:

йорт хайваннарын сату, аларны әлеге территориядән читкә чыгару һәм кыргый җәнлекләр (аларны зоопаркларга чыгару, башка районнарда үрчетү максатларында) тоту;

котыру авырулы яисә авыру дигән шик тудыра торган хайваннарны ит өчен суюю;

котыру авырулы терлекләрнең сөтен сату, ризыкка куллану һәм хайваннарга ашату;

клиник сәламәт терлекләрнең билгеләнгән тәртиптә пастеризацияләнмәгән сөтен сату, ризыкка куллану һәм хайваннарга ашату;

клиник сәламәт терлекләрнең билгеләнгән тәртиптә дезинфекцияләнмәгән йонын, тиресен әлеге территориядән чыгару.

3. Карантин, зарури чаралар күрү шарты үтәлгәндә, терлекләрнең котыру белән чирләвенең соңгы очрагы көненнән ике ай вакыт узгач бетерелергә тиеш, дип билгеләргә.

4. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының Баш ветеринария идарәсенә әлеге Указның 1 пунктында күрсәтелгән территориядә терлекләрнең котыру белән чирләвен бетерү буенча чаралар планын эшләргә һәм расларга, шулай ук аның гамәлгә ашырылуын тәэмин итәргә.

5. Әлеге Указның үтәлешенә контрольне Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына йөкләргә.

6. Әлеге Указ аңа кул куйган көннән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы**
**Президенты** **Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2019 ел, 15 март
№ ПУ-166